**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» апреля 2019 с. Тюлячи № 265

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 апрелендәге «Теләче муниципаль районы балалары һәм яшьләренең ялын оештыру турында»гы 251 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. «2019 елга Теләче муниципаль районы балалары һәм яшьләренең ялын оештыру турында»гы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 апрелендәге 251 номерлы карарына, 3 пунктны түбәндәгечә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Теләче муниципаль районындагы социаль яклау бүлегенә (Галимова Ф.М.), Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә (Гыйниятуллин И.С.), «Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә (Карпова Н.В.) иң беренче чиратта ятим балалар, инвалид балалар, аз керемле, күп балалы һәм тулы булмаган гаиләләрдәге балалар, качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр гаиләләреннән булган балалар ялын оештыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ә. Нурмөхәмәтовка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин